СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«_12_ »___июль____ 2016 ел** **№ __57__**

**2016 елда Арча муниципаль районы җирлекләренең генераль планнарын әзерләү һәм раслау кирәклеге булмау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Арча муниципаль районы җирлекләре территориясендә әлеге җирлекләр территорияләреннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавын һәм аларның комплексды социаль-икътисадый үсешенең расланган программалары, шулай ук Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы территориаль планлаштыру документлары нигезендә федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны тиешенчә урнаштыру каралмавын исәпкә алып, Арча район Советы карар кылды:

1. Арча муниципаль районының түбәндәге авыл җирлекләренең 2016 елда генераль планнарын әзерләү һәм раслау кирәк булмавын танырга:

- Апаз авыл җирлеге;
- Кәче авыл җирлеге;
- Наласа авыл җирлеге;
- Яңа Кенәр авыл җирлеге;
- Яңа Кишет авыл җирлеге;
- Яңа Кырлай авыл җирлеге;
- Сеже авыл җирлеге;
- Урта Курса авыл җирлеге;
- Иске Чүриле авыл җирлеге;
- Ташкичү авыл җирлеге;
- Үрнәк авыл җирлеге;
- Утар Аты авыл җирлеге;
- Шушмабаш авыл җирлеге.

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе И.Ә. Галимуллинга йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И. Г. Нуриев